УДК 908

*Д.И. Әхмәтов*

# «КЕРӘШЕН СҮЗЕ» ГАЗЕТАСЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ МӨХӘРРИРЕ А.Н. МАЛОВ: ЗАМАНДАШЛАРЫНЫҢ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

Статья посвящена известному кряшенскому общественному деятелю, писателю и поэту, первому редактору газеты «Керәшен сүзе» («Кряшенское слово»), издававшейся в 1993–2001 гг. в городе Набережные Челны на татарском и русском языках, Ананию Нестеровичу Малову (литературный псевдоним – Ямаш Игеней; 1938–1997). А.Н. Малов проработал в газете с 1993 по 1997 г. Издание газеты под руководством Анания Малова стало ключевым фактором в популяризации кряшенской культуры, открыв ее как для самой кряшенской общины, чье стремление к собственному изданию длилось более 60 лет, так и для широкой общественности Татарстана. Глубокая личная вовлеченность Анания Несторовича в каждый номер газеты обеспечивала ее теплое восприятие читателями. Цель данной статьи – проанализировать материалы, собранные в газете «Керәшен сүзе» в память о А.Н. Малове. В этих публикациях представлены взгляды и размышления известных писателей, журналистов, общественных деятелей и других авторитетных лиц. Как отмечает автор статьи, Ананий Нестерович Малов оставил светлую память о себе среди современников и молодого поколения.

**Ключевые слова:** газета «Керәшен сүзе», Ананий Нестерович Малов, Ямаш Игеней

This article is dedicated to Ananiy Nesterovich Malov (pen name Yamash Igeney) (1938–1997), a renowned Kryashen public figure, writer, and poet, the first editor of the newspaper «Kerəshen sүze» («Kryashen Word»), published in Naberezhnye Chelny in Tatar and Russian from 1993 to 2001. A.N. Malov worked at the newspaper from 1993 to 1997. The publication of the newspaper under Ananiy Malov's leadership became a key factor in the popularization of Kryashen culture, opening it up to both the Kryashen community itself, whose desire for its own publication lasted for over 60 years, and the general public of Tatarstan. Ananiy Nesterovich's deep personal involvement in each issue of the newspaper ensured its warm reception by readers. The purpose of this article is to analyze materials collected in the newspaper "Kerəshen suzė" in memory of A.N. Malov. These publications present the views and reflections of renowned writers, journalists, public figures, and other authoritative figures. As the author notes, Ananiy Nesterovich Malov left a lasting legacy among his contemporaries and the younger generation.

**Keywords:** newspaper "Kerəshen Süze" ("Kryashen Word"), Anany Nesterovich Malov, Yamash Igeney

Талантлы шагыйрь, публицист, «Керәшен сүзе» газетасының беренче баш мөхәррире, керәшен халкының күренекле улы, зыялы кеше Ананий Нестерович Малов (әдәби псевдонимы – Ямаш Игәнәй; 1938–1997) турында халыкта бары тик җылы истәлекләр

генә сакланган. Әдипнең вафатыннан соң озак та үтми, «Керәшен сүзе» газетасы аның замандашлары, хезмәттәшләре, авылдашлары һәм дусларының истәлекләрен бастыра башлый.

Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре керәшен мәдәни-этнографик җәмгыяте әгъзасы Виктор Шадринның хәтерендә Ананий Малов «туган халкының рухи кыйммәтләрен өйрәнүгә һәм аларны якты киләчәккә юнәлтүгә ярдәм иткән кеше» буларак сакланган. Аның шигырьләрен һәм әсәрләрен дәвамчылары әле озак еллар хәтерләрендә саклаячак дип ышана Виктор Шадрин [3].

«Керәшен сүзе» битләрендә Ананий Малов һәм аның эшчәнлеге турында иң җылы истәлекләрне аның варисы – газетаның икенче баш мөхәррире Людмила Белоусова һәм басманы нигезләүче Николай Антонов калдырган. Л.Д. Белоусова Ананий Нестерович белән ничек танышуын һәм үзенең «Керәшен сүзе» газетасында эшли башлаган көннәрен искә ала: «Ул вакытта без әле иҗтимагый башлангычларда эшли идек, ял көннәрендә яки кичләрен очраша һәм газета әзерли идек» [1].

1995–1998 елларда «Аргамак» журналының баш мөхәррире булган Мансур Мортазин сүзләренә караганда, редакция әгъзаларының барысы да Ананий Маловны яраткан һәм хөрмәт иткән. А.Н. Маловның һәрчак хезмәттәшләре өчен «өлкән иптәш һәм укытучы, шулай ук кыйммәтле киңәшләр биргән акыллы остаз» булуын искә ала ул [2].

Ананий Маловның үзе яшәгән чорны мактамавын, киресенчә, «чынбарлыкны, тормышны ничек бар, шулай чагылдырырга тырышуын» ассызыклый М. Мортазин [6]. Аның фикеренчә, Ананий Нестерович үзенең язмаларында авторлар һәм зыялыларның иҗади потенциаллары кимүгә, шулай ук югары җитәкчелек арасында бюрократиянең урын алуына ризасызлык белдергән.

1995–2000 елларда «Аргамак» журналының баш мөхәррир урынбасары булып эшләгән Мансур Сафин Мамадыш шәһәрендә А. Малов белән бергә эшләгән вакытларын бик җылы хисләр белән искә ала. «Көндәлек уңайсызлыкларга карамастан, Ананий Нестеровичның Мамадыштагы иҗат эшчәнлеге уңышлы булды, анда ул шагыйрь буларак ныгыды, профессиональ язучы булып өлгерде. Без чын шагыйрьләр булырга хыялландык, һәм ул чыннан да үз хыялын тормышка ашырды», – дип нәтиҗә ясый М. Сафин [7].

«Керәшен сүзе» газетасы журналисты, җәмәгать эшлеклесе Рафаэль Сальмушев 1983 елда Ананий Малов белән Татарстан Республикасының Сарман авылында булган тәүге күрешүләрен искә төшереп болай яза: «Малов белән безнең өч көнлек очрашу миндә аның кешеләргә карата игътибарлы, ярдәмчел булуы турында фикер калдырды. Ул – хезмәтләре белән халык мәхәббәтен яулаган чын шагыйрь» [5].

«Аргамак» журналы хезмәткәре Рәшит Бәшәр Ямаш Игәнәйнең бик самими җанлы кеше булуын ассызыклый. Шул самимилеге

өчен Ямаш Игәнәйне кайвакыт үртәргә һәм рәнҗетергә дә тырышканлыкларын, моны әдипнең авыр кабул итүен искәртә. Шушы ук язмасында Р. Бәшәр Ямаш Игәнәйнең хатынына булган көчле мәхәббәтен тасвирлый. Я. Игәнәй барлык өй эшләрен һәм мәшәкатьләрен үз өстенә алган, шулай ук ул авырганда караган, тәрбияләгән [1].

1998 елның 21 мартында Ананий Малов турында эчкерсез, матур сүзләр бер урынга җыелган күпсанлы абруйлы шәхесләр тарафыннан әйтелә. Бу көнне шагыйрьнең туган җирендә – Татарстан Республикасының Сарман районы Ләке авылында бөек керәшен шагыйренең тууына 60 ел тулу билгеләп үтелә. Республикабызның Казан, Яр Чаллы, Алабуга, Менделеевск шәһәрләреннән, Мамадыш районыннан, шулай ук Башкортстанның Бакалы районыннан, Удмуртиянең Ижау шәһәреннән шагыйрь иҗатын яратучылар, аны хөрмәт итүчеләр һәм әдипнең тарафдарлары җыела. Кунаклар арасында Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗев, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге рәисе урынбасары Данил Салихов, «Керәшен сүзе» газетасының баш мөхәррире Людмила Белоусова, танылган җырчы Галина Казанцева була. Очрашуда Татарстан Республикасы Язучылар берлеге рәисе урынбасары Данил Салихов Татарстан китап нәшриятында тиздән шагыйрьнең шигырьләр җыентыгы дөнья күрәчәген хәбәр итә. «Аргамак» журналының баш мөхәррире Мансур Мортазин журнал җитәкчелеге һәм «Рухият» фонды тарафыннан уздырылган әдәби конкурс нәтиҗәләре буенча Ямаш Игәнәйгә 1997 ел өчен Саҗидә Сөләйманова исемендәге премия бирелүен игълан итә.

Күренекле керәшен шагыйре, журналист А.Н. Маловның исемен мәңгеләштерү юнәлешендә дә эшчәнлек алып барыла. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы башлыгы Әнвәр Залаков карары нигезендә шагыйрь укыган Ләке урта мәктәбенә Ямаш Игәнәй исеме бирелә, бер бүлмәсендә шагыйрьнең музее ачыла, анда аның шәхси әйберләре, кульъязмалары, китаплары, утырган партасы, хәтта сыйныф журналлары һәм билгеләр табеле саклана.

1998 елның июлендә Яр Чаллыда Ананий Маловның туган йортында тантаналы рәвештә истәлек тактасы урнаштырыла.

Ямаш Игәнәй вафатыннан соң «Керәшен сүзе» газетасы битләрендә аның авылдашлары үзләренең якты истәлекләрен бастыруны дәвам итәләр. Мәсәлән, Роза Аксакова: «Ананий безнең авылның горурлыгы иде. Һәр җәй ул авылга кайта, туганнары, дуслары, сыйныфташлары белән аралаша иде», дип искә ала [7]. «Мәктәптә укыганда ук шигырьләр, стенгазетага мәкаләләр яза иде. Яшь егет булганда да авылда иң тәртипле һәм тыйнак кешеләрнең берсе булып калды. «Керәшен сүзе» газетасында басылган күп мәкаләләрен Ананий Малов авылга, авылдашларына багышлады. Ул авылны «уятырга», кешеләргә ышаныч бирергә, күзләрен ачарга, кем һәм нинди нәселдән булуларын күрсәтергә тырышты», – дип язалар авылдашлары [7].

2023 елның 14 ноябрендә Казан шәһәрендә Я.Е. Емельянов исемендәге мәдәният үзәгендә «Керәшен сүзе» газетасының

30 еллыгына, аның беренче баш мөхәррире Ямаш Игәнәйнең тууына 85 ел тулуга багышланган «Постсовет чорында керәшеннәрнең вакытлы матбугатын үстерү» Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе оештырыла. Конференциянең максаты «Керәшен сүзе» газетасының барлыкка килүен, аның мөхәррирләре һәм журналистлары эшчәнлеген тулаем өйрәнүдән гыйбарәт була. Анда керәшеннәрнең вакытлы матбугаты үсеше, «Керәшен сүзе» газетасының оештырылу тарихы, беренче баш мөхәррире Ананий Нестерович Маловның эшчәнлеге һәм иҗаты һ. б. мәсьәләләр тикшерелә. Конференциядә Мәскәү, Санкт-Петербург, Казан шәһәрләреннән, Башкортстан Республикасыннан һәм башка төбәкләрдән керәшеннәрнең тарихы һәм мәдәнияте белән бәйле мәсьәләләрне тикшерү белән шөгыльләнгән зыялылар катнаша.

Шулай итеп, Ананий Нестерович Малов – Ямаш Игәнәй – керәшен татарларының иң күренекле вәкилләреннән берсе. Бу талантлы шагыйрь, «Керәшен сүзе» газетасының баш мөхәррире үзе һәм иҗаты турында якты хатирәләр генә калдырды. 2023 елда А.Н. Маловның шигырьләр җыентыгы басылып чыкты [4]. Китап Я. Емельянов исемендәге мәдәни үзәк җитәкчелеге тарафыннан шагыйрь, публицист, журналист, Татарстан язучылар берлеге әгъзасы Ямаш Игәнәйнең тууына 85 ел тулу уңаеннан әзерләнде. Китапта шагыйрьнең үзе исән чакта дөнья күрергә өлгермәгән шигырьләре дә урын алды.

**Чыганаклар һәм әдәбият**

1. *Бәшәр Р.* Сабый җанлы шагыйрь // Керәшен сүзе. 1998. № 1 (39). 23 гыйнв.

2. *Данилова Л.* Исемнәре кайтты әйләнеп // Керәшен сүзе. 1998. № 5 (43). 4 апр.

3. *Колчерин Н.К. һ. б.* Ананий Нестерович Малов (Ямаш Игәнәй) // Керәшен сүзе. 1997. № 3 (29). 24 март.

4. *Малов А.Н.* (Ямаш Игәнәй). Изгелеккә әйдәр уем. Шигырьләр. Казан: «Школа» редакция-нәшрият үзәге, 2023. 420 б.

5. *Моратова Ф.* Ямаш Игәнәй истәлеген мәңгеләштереп // Керәшен сүзе. 1998. № 11 (49). 17 июль.

6. *Сальмушев Р.* Ямаш Игәнәй белән очрашу // Керәшен сүзе. 1998. № 9 (47). 12 июнь.

7. *Шабалин А., Абрамов В.* По велению времени // Керәшен сүзе. 2001. № 5–9 (107–111). Август.

***Әхмәтов Данир Илгизәр улы,***
*тарих фәннәре кандидаты, ТР ФА Экология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану проблемалары институты кече фәнни хезмәткәре*

***Ахметов Данир Ильгизарович,***
*кандидат исторических наук, младший научный сотрудник Института проблем экологии и недропользования АН РТ*

*ahmetov-danir@mail.ru*